МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

01.10.2021 Казан шәһәре 709

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 15 октябрендәге 7989 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 22 сентябрендәге 670 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында, боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 22 сентябрендәге 670 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 19.07.2016 №412, 08.06.2017 №348, 25.01.2018 №60, 07.05.2018 № 348, 18.09.2018 №885, 02.07.2019 №509, 14.11.2019 №1016, 07.02.2020 №80, 01.09.2020 №605, 22.12.2020 №885, 02.06.2021 №385, 06.08.2021 №564 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
2021 елның 1 октябрендәге 709
номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 22 сентябрендәге 670 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү (бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү (бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (кушымтада бирелә) (алга таба – Регламент) расларга.»;

әлеге боерык белән расланган административ регламентта (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү (бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге Административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү (бирү) буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.»;

1.4.1 пунктта беренче абзацта «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең» сүзләреннән соң «(функцияләрнең)» сүзен өстәргә, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы)» сүзләренә алмаштырырга.

түбәндәге эчтәлекле 1.4.3 – 1.4.7 пунктларын өстәргә:

«1.4.3. Мөрәҗәгать итүче телдән (шәхсән яки телефон аша) мөрәҗәгать иткән очракта Идарәнең (бүлекнең) консультация бирә торган белгече мөрәҗәгать итүчеләргә кызыксындырган сораулар буенча тулы һәм нәзакатьле (корректлы) формада мәгълүмат бирә.

Телефон мөрәҗәгатенә җавап бирү мөрәҗәгать итүче шалтыраткан органның атамасы, телефоннан мөрәҗәгатьне кабул иткән белгечнең фамилиясен, исемен,

атасының исемен (соңгысы – булган очракта) һәм вазыйфасын әйтүдән башланып китә.

Әгәр Идарә (бүлек) бүлекчәсе белгече мөстәкыйль рәвештә җавап бирә алмый икән, телефон аша алынган мөрәҗәгать башка вазыйфаи затка адресланырга (күчерелергә) тиеш яисә мөрәҗәгать иткән затка кирәкле мәгълүматны алу мөмкинлеге булган телефон номеры турында хәбәр ителергә тиеш.

Җавапны әзерләү берникадәр вакыт таләп иткән очракта, ул мөрәҗәгать итүчегә эш итүнең түбәндәге вариантларын тәкъдим итә:

мөрәҗәгатьне язма рәвештә бәян итәргә;

консультацияләр өчен башка вакыт билгеләргә.

Идарә (бүлек) белгече дәүләт (муниципаль) хезмәте күрсәтүнең стандарт процедуралары һәм шартлары кысаларыннан чыга торган һәм турыдан-туры яки читләтеп кабул ителә торган карарга йогынты ясый торган мәгълүматларны бирергә хокуклы түгел.

Телефон аша мәгълүмат җиткерү вакыты 10 минуттан артмаска тиеш.

Мәгълүмат җиткерү гражданнарны кабул итү графигы нигезендә башкарыла.

1.4.4. Язмача мөрәҗәгать буенча Идарәнең (бүлекнең) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы белгече мөрәҗәгать итүчегә «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль законда (алга таба – 59-ФЗ номерлы федераль закон) билгеләнгән тәртиптә әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) күрсәтелгән мәсьәләләр буенча белешмәләрне язмача формада җентекләп аңлата.

1.4.5. Бердәм порталда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүне (функцияләрне гамәлгә ашыруны) тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системалары турында» 2011 елның 24 октябрендәге 861 номерлы карары белән расланган «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү (функцияләр) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәдә каралган белешмәләр урнаштырыла.

1.4.6. Идарәнең (бүлекнең) көтү залларында дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актлар, шул исәптән мөрәҗәгать итүче таләбе буенча аңа танышу өчен бирелә торган Регламент урнаштырыла.

1.4.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны карау барышы хакында һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) тарафыннан Бердәм порталдагы шәхси кабинет аша, шулай ук, мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, Идарәдән (бүлектән), телефон буенча, электрон почта аша алынырга мөмкин.»;

2 бүлектә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү (бирү).»;

2.3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар, социаль контракт нигезендә дәүләт

социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар (әлеге Регламентның 5 нче кушымтасы).»;

2.3.2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«электрон документ формасында – электрон почта адресына һәм мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталдагы, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына;»;

2.4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.3. Кабул ителгән дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) шәхесне таныклый торган документ (Идарәгә (бүлеккә) күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә күрсәтелә);

2) мөрәҗәгать итүченең гаилә һәм матди-көнкүреш хәле турында гариза һәм анкета:

әлеге Регламентка 1 нче, 2 нче кушымталар нигезендә кәгазь документ формасында;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы һәм Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә, электрон формада (Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында һәм Бердәм порталда, гаризаны нинди дә булса башка төрле формада өстәмә тапшыру зарурлыгыннан башка гына) интерактив форманы тутыру юлы белән), әлеге пункт таләпләре нигезендә имзалап;

3) керемнәрне раслый торган документлар (мөрәҗәгать итүченең керемнәре булган очракта);

4) белем алу турында документ (мөрәҗәгать итүче яки аның гаилә әгъзалары белем алган очракта);

5) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча мөрәҗәгать итүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче вәкиленең мәнфәгатьләрен таныклый торган документ (физик затларның законлы вәкилләреннән тыш);

6) чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе;

7) өйләнешүне (аерылышуны) дәүләт теркәвенә алу турында чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе;

8) сак астына алу турында суд карары (гаилә әгъзасын сак астына алган очракта);

9) мәҗбүри дәвалау турында суд карары (гаилә әгъзасы мәҗбүри дәвалануда булганда);

10) туганлык мөнәсәбәтләрен раслый торган суд карары (туганлык мөнәсәбәтләре судта расланган очракта);

11) тулысынча дәүләт тәэминатында тору турында документ;

12) янгын, су басу яисә башка табигый бәла-казалар нәтиҗәсендә авыр тормыш хәленә бәйле рәвештә дәүләт социаль ярдәмен алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта, өстәмә рәвештә хәлләрнең килеп чыгуын раслаучы документлар (актның күчермәләре, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы бүлекчәсеннән булган факт турында белешмә) тапшырыла.

Гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең шәхесен таныклый торган документындагы белешмәләре исәпкә алыну язуы ИАБС расланган вакытта тикшерелә.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, юридик зат тарафыннан бирелгән документ документны биргән вәкаләтле затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, шәхси эшкуар тарафыннан бирелгән документ шәхси эшкуарның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, нотариус тарафыннан бирелгән документ нотариусның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш. Башка очракларда – гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш.

2.5.2. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

1) күпфункцияле үзәк аша кәгазьдә һәм «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә, мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затлар тарафыннан, шул исәптән нотариус тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә;

2) Идарәгә (бүлеккә) шәхсән яисә почта аша кәгазьдә җибәреп;

3) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Бердәм порталда шәхси кабинет аша гариза формасын тутыру юлы белән Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша электрон формада;

4) гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша (алга таба – «Интернет» челтәре).

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Идарә (бүлек), күпфункцияле үзәк белгече тарафыннан таныклана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Идарәгә (бүлеккә), күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урынына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гаризаны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да җибәргән очракта, гариза һәм электрон документ формасында документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.

2.5.3. Мөрәҗәгать итүчеләр, гаризаны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре ярдәмендә, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалыйлар. Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.»;

2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.1. Вәкаләтле органнардан ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәге белешмәләр алына:

1) мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документның чын булуын раслый торган (иске паспортлары белән паспорт досьесы);

2) яшәү урыны яки тору урыны буенча теркәлү исәбе турында;

3) яшәү (вакытлыча тору) урыны буенча мөрәҗәгать итүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында;

4) хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру факты турында;

5) шәхси счетның иминият номеры турында;

6) эшсез сыйфатында теркәлү, эшсезлек буенча пособие алу һәм аның күләме турында (стипендияләр һәм башка түләүләр);

7) компенсация түләүләре (эшләми торган хезмәткә сәләтле, хезмәткә сәләтсез затларны караучы затларга түләнә торган компенсация түләүләреннән тыш) һәм Россия Федерациясе Пенсия фондыннан пенсионерларга ай саен өстәмә матди түләүләрнең алынуы һәм күләмнәре турында;

8) хәрби хезмәткәрләр ала торган пенсия күләме турында;

9) пенсия алу, аны билгеләү, алмау һәм түләүләрнең туктатылуы турында;

10) йөклелек һәм бала табу буенча  социаль яклау органнары яисә Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнары тарафыннан түләнә торга нпособие күләме турында;

11) вакытлыча эшкә сәләтсез булган чордагы пособие күләме турында;

12) йөклелекнең башлангыч чорында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга  социаль яклау органнарыннан яки Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнарыннан бер тапкыр бирелә торган пособие күләмнәре турында;

13) бала карау буенча социаль яклау органнары яисә Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнары тарафыннан ай саен түләнә торган пособие күләмнәре турында;

14) җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса;

15) социаль яклау органнары тарафыннан түләнә торган социаль түләүләрнең барлык төрләренә өстәп түләү һәм өстәмәләр күләме турында;

16) Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән, социаль яклау органнарыннан түләнә торган башка төрле социаль түләүләрнең күләмнәре турында;

17) бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

18) өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында;

19) аерылышуны дәүләт теркәвенә алу турында;

20) опека (химаяче) билгеләү һәм опекунның (химаяченең) баланы асрауга акча алуы турында;

21) баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру һәм тәрбиягә алучы ата-аналарга тиешле түләү суммалары турында;

22) мөрәҗәгать итүченең ата-ана хокукыннан мәхрүм ителүе турында яисә ата-ана хокукында чикләнүе турында;

23) мөрәҗәгать итүчедә һәм аның гаилә әгъзаларында Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында булган күчемсез мөлкәт булуы турында;

24) билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урыны турында;

25) мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының транспорт чаралары булуы турында;

26) хезмәт һәм башка бурычларны үтәгән өчен түләү, шул исәптән кызыксындыру характерындагы түләүләр, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт өчен бүләкләү, гражданлык хокукы килешүе кысаларында гамәлләр кылган өчен бүләкләү турында;

27) дивидендлар, шулай ук кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр буенча алынган процентлар турында;

28) эшкуарлык эшчәнлегеннән һәм шәхси практиканы гамәлгә ашырудан алынган керемнәр турында;

29) авторлык заказы, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукны читләштерү турындагы килешүләр буенча алынган керемнәр турында;

30) сатудан кергән табыш турында;

31) ышаныч кәгазе бирү һәм аның эчтәлеге турында;

32) 18 яше тулмаган инвалид баланы яки балачактан ук I төркем инвалидны яки хезмәткә сәләтсез затларны карый торган затлар турында;

32) мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзаларының иректән мәхрүм итү урынынннан (урыннарыннан) чыгарылуы (тотылуы) турында;

34) гаиләнең башка әгъзалары тарафыннан дәүләт социаль ярдәменең алынмаган булуы турында;

35) вафат булу турында;

36) фамилияне, исемне, ата исемен үзгәртү турында;

37) аталыкны билгеләү турында;

38) фамилия-исем төркемнәренең, туу датасының, җенеснең һәм СНИЛС туры килүе турында.

Мөрәҗәгать итүче Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча өстәмә рәвештә мөрәҗәгать итүче паспортының чын булуын раслау турындагы белешмәләр алына.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүче, гаризаны Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша биргәндә, әлеге Регламентның 2.6.1 пунктының 1-38 пунктчаларында күрсәтелгән документларны (белешмәләрне) үз инициативасы белән мондый документларны төзү һәм имзалау өчен вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документлар формасында җибәрергә яисә Идарәгә (бүлеккә), күпфункцияле үзәккә кәгазьдә тапшырырга хокуклы.

Әлеге белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмаларда, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алынырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.3. Дәүләт хакимияте органнары тарафыннан документлар һәм мәгълүматның тапшырылмавы (вакытында тапшырылмавы) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе була алмый.

2.6.4. Идарә (бүлек) мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны

кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.»;

2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезе:

1) Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы;

2) тапшырылган документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган һәм текстны төзәткән урыннар булуы;

3) дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы мәгълүматлар булган документлар тапшырылуы;

4) тапшырылган документларның хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү вакытына көчен югалтуы (шәхесне таныклый торган документ, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ, – хезмәт күрсәтүне сорап әлеге зат мөрәҗәгать иткән очракта).

5) документларда хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булуы.

6) хезмәт күрсәтү турындагы гаризаның хезмәт күрсәтүгә вәкаләтле булмаган дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яисә оешмага тапшырылуы;

7) гариза формасында, шул исәптән Бердәм порталда гаризаның интерактив формасында, кырларның тулысынча тутырылмавы;

8) әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр категорияләренә керми торган затка дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү;

9) гаризаның мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләте булмаган зат тарафыннан бирелүе;

10) формасы һәм эчтәлеге буенча Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килми торган документларның тапшырылуы;

11) Идарәгә (бүлеккә) гариза һәм 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә гади электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) документларны (документларның күчермәләрен) тапшыру (гаризаны электрон формада тапшырган очракта).

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең исемлеге тулы булып тора.

2.7.3. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары

һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм башка документларны кабул итүдән баш тарту рөхсәт ителми.»;

2.8.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5-7 пунктчалар өстәргә:

«5) мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүченең гаиләсенең) хезмәт күрсәтү хокукына ия булган гражданнар (гаиләләр) категориясенә карамавы;

6) мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең гаиләсенә) карата дәүләт социаль ярдәмен билгеләү турындагы карарның агымдагы елда алданрак кабул ителгән булуы;

7) элек төзелгән социаль контрактның гамәлдә булу чорының бетмәве.»;

2.16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.16.1. Дәүләт хезмәтен экстерриториаль принцип буенча күрсәтү гаризаларны Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрү мөмкинлеген тәэмин итү өлешендә гамәлгә ашырыла.

2.16.2. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Идарә (бүлек), шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.16.3. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Бу очракта мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында ИАБС системасында исәпкә алыну язуын

раслау юлы белән авторизация уза, электрон рәвештә интерактив формадан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тутыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында тутырылган гариза, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон рәвешләрен теркәп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Идарәгә (бүлеккә) җибәрелә. ИАБС системасында авторизацияләнгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза мөрәҗәгать итүченең, гаризаны имзалау өчен вәкаләтле мөрәҗәгать итүче вәкиленең гади электрон имзасы белән имзаланган дип санала.

Гариза Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелгән очракта, әлеге Регламентның 2.3 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә, мөрәҗәгать итүченең вәкиленә Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинетка Идарә (бүлек) җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ формасында җибәрелә.

2.16.4. Электрон документлар түбәндәге форматларда тапшырыла:

а) xml - формалаштырылган документлар өчен;

б) doc, docx, odt - формулалары булмаган, текстлы эчтәлектәге документлар өчен (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш);

в) xls, xlsx, ods - исәпләмәләре булган документлар өчен;

г) pdf, jpg, jpeg - формулаларны һәм (яки) график сурәтләрне дә үз эченә алган (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш), шулай ук график сурәтләре булган документларны да кертеп, текстлы эчтәлектәге документлар өчен.

Документның үз оригиналын сканер аша уздыру юлы белән электрон документны формалаштыру рөхсәт ителә (күчермәләрне куллану рөхсәт ителми), ул 300 - 500 dpi (масштаб 1:1) мөмкинлегендә документ оригиналы ориентациясен саклап гамәлгә ашырыла, түбәндәге режимнарны кулланып:

«каралы-аклы» (документта график сурәтләр һәм (яки) төсле текст булмаган очракта);

«соры төсмерләрдә» (документта төсле график сурәтләрдән аерыла торган график сурәтләр булган очракта);

«төсле» яки «төсне тулы дәрәҗәсендә тапшыру режимы» (документта төсле график сурәтләр яисә төсле текст булган очракта);

чын нөсхәдәге барлык аутентик билгеләрне, атап әйткәндә: затның график имзасын, мөһерне, бланк чатындагы штампны саклап;

файллар саны һәркайсында текстлы һәм (яки) графикалы мәгълүматлар булган документлар санына туры килергә тиеш.

Электрон документлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

документны һәм документтагы битләр санын идентификацияләү мөмкинлеген;

өлешләргә, бүлекләргә, кисәкләргә (кискәчләргә) бүленгән документлар өчен эчтәлек буенча һәм (яки) текстта булган рәсемнәргә һәм таблицаларга күчү мөмкинлеген.

xls, xlsx яки ods форматларында тапшырылырга тиешле документлар аерым электрон документ рәвешендә формалаштырыла.

2.16.5. Мөрәҗәгать итүчеләрне Идарәгә (бүлеккә) кабул итүгә язу (алга таба – язу) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Идарә (бүлек) телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Идарәдә (бүлектә) билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына языйлу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу барышында күрсәтелгән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылган вакытта, мөрәҗәгать итүчегә үзе тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул белән, әгәр дә ул кабул итү өчен билгеләнгән вакыттан соң 15 минут узгач килмәсә, алдан язылуның гамәлдән чыгарылачагы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша яки Идарә (бүлек) телефоны буенча алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

Гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәрелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша гариза биргәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе электрон формада бирелә.»;

3 нче бүлектә:

3.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт социаль ярдәмен, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:»;

3.1 пунктның 7 һәм 8 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар, контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү;

8) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен гражданин шәхсән мөрәҗәгать иткәндә (гаризаны һәм документларны почта аша җибәргәндә) бирү яки дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетта урнаштыру.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, Мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмат алу;

гариза формалаштыру;

гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәүгә алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу;

гариза карау барышы турында мәгълүмат алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү;

дәүләт хезмәтен күрсәтә торган Идарә (бүлек) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) яисә Идарәнең (бүлекнең) вазыйфаи затлары яки дәүләт хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү.

Гаризаны карау барышы турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алу, авторизацияләнү шарты белән, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинетта гамәлгә ашырыла. Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта үз инициативасы буенча шәхси кабинетта электрон гаризаның статусын, шулай ук алга таба башкарылачак гамәлләр турында мәгълүмат карау мөмкинлегенә ия.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләр җибәрелә:

а) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итү һәм теркәү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының башлану факты турындагы белешмәләрне, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүне тәмамлау датасы һәм вакыты турындагы белешмәләрне яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән нигезле баш тартуны үз эченә алган белдерү;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карау нәтиҗәләре турында белдерү, анда дәүләт хезмәте күрсәтү турында уңай карар кабул ителүе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе алу мөмкинлеге турында белешмәләр яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезле баш тарту була.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.»;

3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче, әлеге Регламентның 2.5.1 пункты нигезендә документларны теркәп, дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза тапшыра.

Социаль контракт төземичә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү турында әлеге Регламентның 1 кушымтасындагы форма буенча гариза биргән очракта, әлеге Регламентның 1.2 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өстәмә рәвештә әлеге Регламентның 2.5.1 пунктының 12 пунктчасында күрсәтелгән документларны да тапшыралар.

Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү турында гариза биргәндә – әлеге Регламентның 2 нче кушымтасындагы форма буенча.

Законнарда каралган тәртиптә расланган гариза һәм документларның күчермәләре почта аша җибәрелергә мөмкин.

63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә мөрәҗәгать итүченең электрон имзасы белән имзаланган (таныкланган) электрон документ рәвешендәге гариза һәм документларның күчермәләре мөрәҗәгать итүче тарафыннан Идарәгә (бүлеккә) электрон саклагыч җайланмаларыннан файдаланып тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче, гаризаны Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада тапшыру өчен, түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында авторизацияләү уза;

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.5 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Формалаштырылган гаризаны форматы-мантыйгы ягыннан тикшерү мөрәҗәгать итүче гаризаның электрон формасындагы барлык юлларны тутырганнан соң гамәлгә

ашырыла. Гаризаның электрон формасындагы кырларны төгәлсез тутыру очрагы ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры гаризаның электрон формасында мәгълүмат җиткереп, хәбәр ителә.

Гаризаны формалаштырганда мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) гаризаның һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларның күчермәләрен ясау һәм аларну саклау мөмкинлеге;

б) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

в) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гаризаның электрон формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза формасына элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

г) ИАБС булмаган мәгълүматларга кагыла торган өлешендә, ИАБС системасында урнаштырылган һәм Бердәм порталда, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында басылып чыккан мәгълүматларны файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан белешмәләр кертә башлаганчыга кадәр электрон гариза формасы кырларын тутыру;

д) элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гариза формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

е) мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында бер елдан азрак булмаган чорда үзе элегрәк тапшырган гаризаларны, шулай ук кимендә 3 ай эчендә өлешчә формалаштырган гаризаларны карау мөмкинлеге.

Формалаштырылган һәм имзаланган гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар Идарәгә (бүлеккә) Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелә.

Идарә (бүлек) белгече дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, шушы Регламентның 2.7.1 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Идарә (бүлек) белгече өчен электрон гаризаны алу мөмкинлеге «Татарстан Республикасы Халыкның социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасында тәэмин ителә.

Идарә (бүлек) белгече:

Бердәм порталдан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан электрон гаризалар булу-булмавын көненә 2 тапкырдан ким булмаган ешлыкта тикшерә;

алынган гаризаларны һәм теркәлгән документлар рәвешләрен карый.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Идарә (бүлек) белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 4 нче кушымтасы);

мөрәҗәгать итүчегә гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, алганда беркетелгән номеры (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта) турында

тамгалап язу тапшыра, ә гариза почта буенча һәм (яки), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән җибәрелгән очракта, – гаризаны теркәү датасы һәм алынган беркетелгән номеры турында белдерү җибәрә.

Документларны кабул итүдән әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында каралган баш тарту нигезләре булган очракта (шәхсән мөрәҗәгать иткәндә), Идарә (бүлек) белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре турында телдән хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, барлык документларны аңа кайтарып бирә. Гаризаны һәм документларны почта аша һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән алганда, Идарә (бүлек) белгече гаризаны һәм документларны, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту сәбәпләрен язмача аңлатып, кайтарып бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, әлеге Регламентның 2.13 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләрне исәпкә алып, гариза һәм документлар алынган көнне, ә электрон гариза Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша эшләми торган яки бәйрәм көнендә алынган очракта, аннан соңгы беренче эш көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәү язуы, язу яисә мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелгән документлар, мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту турында телдән (язмача) белдерү.

3.3.2. Мөрәҗәгать итүчеләр гаризаны һәм документларның күчермәләрен күпфункцияле үзәк яки аның ерактагы эш урыны аша тапшыра ала.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы заты аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында, әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар теркәп, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына язмача гариза һәм документлар тапшыра.

Күпфункцияле үзәкнең гаризаларны һәм документларны кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән гариза һәм документлар.

3.3.3. Күпфункцияле үзәк белгече гариза һәм документларны Идарәгә (бүлеккә) җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Идарә (бүлек) белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында, үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытларда, ләкин гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарәгә (бүлеккә) җибәрелгән гариза һәм документлар.»;

3.4.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Идарәдә (бүлектә) булмаган очракта, Идарә (бүлек) белгече, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада да, вәкаләтле органнардан белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр юллый:

1) мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документның чын булуын раслый торган (иске паспортлары белән паспорт досьесы);

2) яшәү урыны яки тору урыны буенча теркәлү исәбе турында;

3) яшәү (вакытлыча тору) урыны буенча мөрәҗәгать итүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында;

4) хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру факты турында;

5) шәхси счетның иминият номеры турында;

6) эшсез сыйфатында теркәлү, эшсезлек буенча пособие алу һәм аның күләме турында (стипендияләр һәм башка түләүләр);

7) компенсация түләүләре (эшләми торган хезмәткә сәләтле, хезмәткә сәләтсез затларны караучы затларга түләнә торган компенсация түләүләреннән тыш) һәм Россия Федерациясе Пенсия фондыннан пенсионерларга ай саен өстәмә матди түләүләрнең алынуы һәм күләмнәре турында;

8) хәрби хезмәткәрләр ала торган пенсия күләме турында;

9) пенсия алу, аны билгеләү, алмау һәм түләүләрнең туктатылуы турында;

10) йөклелек һәм бала табу буенча  социаль яклау органнары яисә Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнары тарафыннан түләнә торга нпособие күләме турында;

11) вакытлыча эшкә сәләтсез булган чордагы пособие күләме турында;

12) йөклелекнең башлангыч чорында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга  социаль яклау органнарыннан яки Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнарыннан бер тапкыр бирелә торган пособие күләмнәре турында;

13) бала карау буенча социаль яклау органнары яисә Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнары тарафыннан ай саен түләнә торган пособие күләмнәре турында;

14) җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса;

15) социаль яклау органнары тарафыннан түләнә торган социаль түләүләрнең барлык төрләренә өстәп түләү һәм өстәмәләр күләме турында;

16) Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән, социаль яклау органнарыннан түләнә торган башка төрле социаль түләүләрнең күләмнәре турында;

17) бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

18) өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында;

19) аерылышуны дәүләт теркәвенә алу турында;

20) опека (химаяче) билгеләү һәм опекунның (химаяченең) баланы асрауга акча алуы турында;

21) баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру һәм тәрбиягә алучы ата-аналарга тиешле түләү суммалары турында;

22) мөрәҗәгать итүченең ата-ана хокукыннан мәхрүм ителүе турында яисә ата-ана хокукында чикләнүе турында;

23) мөрәҗәгать итүчедә һәм аның гаилә әгъзаларында Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында булган күчемсез мөлкәт булуы турында;

24) билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урыны турында;

25) мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының транспорт чаралары булуы турында;

26) хезмәт һәм башка бурычларны үтәгән өчен түләү, шул исәптән кызыксындыру характерындагы түләүләр, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт өчен бүләкләү, гражданлык хокукы килешүе кысаларында гамәлләр кылган өчен бүләкләү турында;

27) дивидендлар, шулай ук кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр буенча алынган процентлар турында;

28) эшкуарлык эшчәнлегеннән һәм шәхси практиканы гамәлгә ашырудан алынган керемнәр турында;

29) авторлык заказы, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукны читләштерү турындагы килешүләр буенча алынган керемнәр турында;

30) сатудан кергән табыш турында;

31) ышаныч кәгазе бирү һәм аның эчтәлеге турында;

32) 18 яше тулмаган инвалид баланы яки балачактан ук I төркем инвалидны яки хезмәткә сәләтсез затларны карый торган затлар турында;

32) мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзаларының иректән мәхрүм итү урыныннан (урыннарыннан) чыгарылуы (тотылуы) турында;

34) гаиләнең башка әгъзалары тарафыннан дәүләт социаль ярдәменең алынмаган булуы турында;

35) вафат булу турында;

36) фамилияне, исемне, ата исемен үзгәртү турында;

37) аталыкны билгеләү турында;

38) фамилия-исем төркемнәренең, туу датасының, җенеснең һәм СНИЛС туры килүе турында.

3.4.1, 3.4.2 пунктчаларда билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон формада алынган мәгълүматлар, мәгълүмат бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

3.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү»;

3.8.1 пунктта:

өченче һәм дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Регламентның 5 нче кушымтасындагы форма буенча дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын рәсмиләштерә;

дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын имзалау өчен Идарә (бүлек) җитәкчесенә җибәрә.»;

3.9 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү Идарә (бүлек) белгече мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар турында гаризада күрсәтелгән ысул (хат, смс-хәбәр, электрон почта, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша) белән хәбәр итә.»;

3.10.1 пунктта:

өченче һәм дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын үзгәртеп рәсмиләштерә;

үзгәртеп рәсмиләштерелгән дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын имзалау өчен Идарә (бүлек) җитәкчесенә җибәрә.»;

3.10.2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.10.2. Идарә (бүлек) җитәкчесе үзгәртеп рәсмиләштерелгән дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын имзалый һәм аны Идарә (бүлек) белгеченә җибәрә.»;

3.10.3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.10.3. Идарә (бүлек) белгече үзгәртеп рәсмиләштерелгән дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карарны, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карарны мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән җибәрә.»;

3.10.4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.10.4. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы заты аша күпфункцияле үзәккә Идарә (бүлек) тарафыннан бирелгән дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карарда, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карарда җибәрегән хәреф хаталарын һәм ялгышларны төзәтү турында язмача гариза тапшыра.»;

Регламентка 1-2 нче кушымталарны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
территориясендә гражданнарның аерым
категорияләренә дәүләт социаль ярдәме
күрсәтү (бирү) буенча дәүләт хезмәте
күрсәтү административ регламентына
1 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш
белән тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының социаль яклау идарәсенә
(бүлегенә)
________________________________________
(муниципаль районында (шәһәр округында))

Дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза

Мин, ______________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча),
яши торган адресы:
_______________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)
_______________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документның исеме, аның сериясе, номеры, бирелү датасы, документны биргән органның атамасы)
Мөрәҗәгать итүченең хосусый шәхси счет номеры ____________
түбәндәгеләрне күрсәтү турында үтенәм:
миңа (минем гаиләмә) (кирәклесе астына сызарга кирәк)
мөрәҗәгать итүчегә (ышанычлы зат мөрәҗәгать иткән очракта тутырыла)
_______________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча)
түбәндәге адрес буенча яши: ____________________________________,
_______________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)
_______________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документның аталышы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы, документны биргән органның аталышы)
дәүләт социаль ярдәме ______________________________________
(күрсәтергә: аз керемле гаилә буларак (аз керемле ялгыз яшәүче гражданин буларак);
_______________________________________________________________.

авыр тормыш хәлендә булган гаилә буларак (ялгыз яшәүче гражданин буларак))

1. Тапшыра торган документлар (белешмәләр):

| | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

2. Гаилә составы:

| | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туганлык мөнәсәбәтләре |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

3. Мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәре турында белешмәләр:

| | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Керем төре | Керем суммасы (сум) |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

4. Мөрәҗәгать итүченеке һәм аның гаилә әгъзаларыныкы булган мөлкәт турында белешмәләр:

| | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Мөлкәт төре | Милекчелек төре |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

5. Дәүләт социаль ярдәменең билгеләнгән суммасын (түләүне):
әлеге счетка күчерергә ________________________________
(мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә)
почта бүлекчәсе аша җибәрергә
______________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең яки законлы вәкилнең почта реквизитлары күрсәтелә)

Тапшырылган мәгълүматларның, аларны үз эченә алган документларның дөрес булуы өчен җаваплылык турында һәм түләүләргә йогынты ясый торган шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турындагы нигезләмәләр белән таныштым ___________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы)

Дөрес булмаган мәгълүматлар белән документлар тапшыру нәтиҗәсендә миңа артык түләнгән акчаларны законнарда билгеләнгән тәртиптә кире түләттерелүе турында кисәтү алдым.

Мәгълүмат, шул исәптән дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында да, алуга риза:
________________________________________ почта адресы буенча язма формада;
____________________________________телефонына смс-хәбәр итеп
(телефон номеры)
әлеге электрон почта адресына электрон документ формасында________________________________________
(электрон почта адресы)
«Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша
______________________________________________________________

Мөрәҗәгать итүче:
________________________________________ __________ «__» ________20__ ел
(мөрәҗәгать итүченең яисә аның мәнфәгатьләрендә (имза)

билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышаныч кәгазе нигезендә
эш итүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы
– булган очракта)

Гариза һәм документлар кабул ителде ______ 20__ ел. _________

______________________________

(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

______________________________________________________________________

Аеру линиясе

Язу-белдерү

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү номеры ____

Документлар саны ____ данә, __ биттә

Документларны кабул итте ____________ __________ _____________ _______________

(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)

«Татарстан Республикасы
территориясендә гражданнарның аерым
категорияләренә дәүләт социаль ярдәме
күрсәтү (бирү) буенча дәүләт хезмәте
күрсәтү административ регламентына 2
нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны
эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының социаль яклау идарәсе
(бүлеге) җитәкчесенә

___________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында)

Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында

ГАРИЗА

Әлеге чараны гамәлгә ашыру өчен:_______________________________________

______________________________________________________________________

(күрсәтелә: эш эзләү; шәхси эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча («Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланганда һөнәри керемгә салым түләүче зат сыйфатында теркәлү буенча); шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, гражданин тарафыннан авыр тормыш хәлен җиңеп чыгуга юнәлдерелгән башка чараларны гамәлгә ашыру буенча))

Мин, _____________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яисә законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча)

яши торган адрес: ________________________________________________

_____________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)

_____________________________________________________________

_____________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документның исеме, аның сериясе, номеры, бирелү датасы, документны биргән орган атамасы)

Мөрәҗәгать итүченең хосусый шәхси счет номеры ______________

түбәндәгеләрне күрсәтү турында үтенәм:

миңа (минем гаиләмә) (кирәклесе астына сызарга кирәк)

мөрәҗәгать итүчегә (ышанычлы зат мөрәҗәгать иткән очракта тутырыла)

_____________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча)

түбәндәге адрес буенча яши: _________________________________________,

_____________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)

_____________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документның аталышы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы, документны биргән органның аталышы)

социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме

_____________________________________________________________

(күрсәтергә: аз керемле гаилә буларак (аз керемле ялгыз яшәүче гражданин буларак);

_____________________________________________________________.

авыр тормыш хәлендә булган гаилә буларак (ялгыз яшәүче гражданин буларак))

_____________________________________________________ рәвешендә

(акчалата түләүләр, социаль хезмәтләр, натураль ярдәм)

Барлык балигъ булмаган гаилә әгъзалары социаль контракт төзүгә риза: контракт:

________________________________ ________________(имза)

________________________________ ________________(имза)

________________________________ ________________(имза)

________________________________ ________________(имза)

Дәүләт социаль ярдәменең билгеләнгән суммасын (түләүне) ____________________________________ счетына күчерергә

_____________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә)

Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен билгеләү өчен мин тапшырган мәгълүматлар тулы һәм дөрес булып тора.

Керемнәрне яшергән һәм дәүләт социаль ярдәмен алу хокукына йогынты ясарлык дөрес булмаган мәгълүматлар белән документлар тапшырган өчен җаваплылык булуы турында кисәтелде. Вәкаләтле орган вәкилләре тарафыннан мин тапшырган мәгълүматларны тикшерүгә һәм гаиләмә килүләренә каршы түгелмен.

Мәгълүмат, шул исәптән социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту, күрсәтүне туктату) турында да, алуга риза:

почта адресы буенча язма формада ______________________

______________________________________ телефонына смс-хәбәр итеп

(телефон номеры)

әлеге электрон почта адресына электрон документ формасында__________________

(электрон почта адресы)

«Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша ___

Кушымта:

1. Гаилә һәм матди-көнкүреш хәле турында анкета (ялгыз яши торган гражданинның) _______ биттә, 1 нөсхәдә.
2. ___

Дата _______________ Мөрәҗәгать итүченең имзасы _________________________
Документлар кабул ителде ____________
Кабул итте _______________________(имза)»;

Регламентка 5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү (бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 5 нче кушымта

Форма

<<___________>>
(вәкаләтле орган атамасы)

Кемгә:

___

*(фамилиясе, исеме, атасының исеме )*

Элемтә өчен мәгълүмат: <<________>>
*(Почта индексы һәм адрес)*
<<______>>

Дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында карар

<<______>> №<<______>>

<<_______>> № <<_______>> гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча «Дәүләт социаль ярдәме» турында 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителде:

<<__________>>, <<________>>
(Фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, ае, елы)

<< ________>> башлап с << ________>> кадәрге чорга яки бер тапкыр << _________>> күләмендә

Өстәмә мәгълүмат: <<________________>>.

{<<______________>> <<_________________>>}  Электрон имза турында белешмәләр

Форма

<<___________ >>
(вәкаләтле орган атамасы)

Кемгә:
_________________________________________
_
*(фамилиясе, исеме, атасының исеме )*

Элемтә өчен мәгълүмат: <<________>>
*(Почта индексы һәм адрес)*
<<______ >>

Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында КАРАР

<<_____ >>  №<<_____ >>

<<_______>> № <<_______>> гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча «Дәүләт социаль ярдәме» турында 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителде:

<<__________>>, <<________>>
(Фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, ае, елы)

<< ________>> башлап с << ________>> кадәрге чорга яки бер тапкыр << _________>> күләмендә

Өстәмә мәгълүмат: <<________________>>.

{<<______________>> <<_________________>>}  Электрон имза турында белешмәләр

Форма

<<__________ >>
(вәкаләтле орган атамасы)

Кемгә:

___________________________________

—

*(фамилиясе, исеме, атасының*

*исеме )*

Элемтә өчен мәгълүмат: <<________>>
*(Почта индексы һәм адрес)*
<<______ >>

Дәүләт социаль ярдәме күрсәтүдән баш тарту турында
КАРАР

<<_____ >> №<<______ >>

<<_______>> № <<_______>> гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча «Дәүләт социаль ярдәме» турында 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде, түбәндәге нигезләр буенча:

-<<__________>>;
- <<__________>>
- << __________>> .

Өстәмә мәгълүмат: <<________________>>.

Әлеге җитешсезлекләрне бетергәннән соң хезмәт күрсәтү турында гариза белән Сез вәкаләтле органга кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Баш тарту турындагы әлеге карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.

{<<______________>> <<_________________>>} Электрон имза турында белешмәләр

Форма

<<__________ >>
(вәкаләтле орган атамасы)

Кемгә:

___________________________________________

(*фамилиясе, исеме, атасының*

*исеме* )

Элемтә өчен мәгълүмат: <<________>>

(*Почта индексы һәм адрес)*

<<_______>>

Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүдән баш тарту турында
КАРАР

<<_____>> №<<_____>>

<<_______>> № <<_______>> гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча «Дәүләт социаль ярдәме» турында 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде, түбәндәге нигезләр буенча:

-<<__________>>;

- <<__________>>

- << __________>> .

Өстәмә мәгълүмат: <<_________________>>.

Әлеге җитешсезлекләрне бетергәннән соң хезмәт күрсәтү турында гариза белән Сез вәкаләтле органга кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Баш тарту турындагы әлеге карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.

{<<______________>> <<_________________>>} Электрон имза турында белешмәләр

«;

Регламентка 6 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү (бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 6 нчы кушымта киңәш ителә торган форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының

________________________________________

Социаль яклау идарәсенә (бүлегенә)

___________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин,

______________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)
яши торган адрес

_________________________________________________________________.

_________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)

_________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ атамасы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы,

_________________________________________________________________,
документны биргән орган атамасы)
техник хатаны төзәтүне сорыйм ___________________________,
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________,
дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карарда, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карарда җибәрелгән __________________ №________________.
карар датасы карар номеры
Дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны ______________________ алырга риза.
(язмача, электрон почта аша)

«__» _____________ 20__ ел. ______________________ _________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)»;

Регламентка түбәндәге эчтәлекле 7 нчы кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү (бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 7 нче кушымта

Форма

<<___________ >>
(вәкаләтле орган атамасы)

Кемгә:

___________________________________

—

*(фамилиясе, исеме, атасының исеме )*

Элемтә өчен мәгълүмат: <<________>>

*(Почта индексы һәм адрес)*

<<______ >>

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (бирү) буенча хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында

КАРАР

<<_____ >> №<<______ >>

<<_______>> № <<_______>> гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча «Дәүләт социаль ярдәме» турында 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде, түбәндәге нигезләр буенча:

<<_________>> <<___________>> <<___________>> <<___________>> <<___________>>

<<__________>> <<__________>> <<__________>> <<__________>>

Өстәмә мәгълүмат: <<________________>>.

Әлеге җитешсезлекләрне бетергәннән соң хезмәт күрсәтү турында гариза белән Сез вәкаләтле органга кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Баш тарту турындагы әлеге карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.

{<<______________>> <<_________________>>} Электрон имза турында белешмәләр

«;

Регламентка 2.1, 3-4 нче кушымталарның нумерацияле баш исемен, белешмәлек кушымтаның баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү (бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына»;

Регламентка (белешмәлек) кушымтаның баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү (бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы булган органнар һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр».